ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.07.2015 г.Казань № 87

**Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибе турында**

2006 елның 02 маендагы “Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү турында” 59-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 12 маендагы “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына гражданнардан мөрәҗәгатьләр килүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм юк итү максатларында **б о е р ы к б и р ә м:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Рәис С.Е.Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының
2015 елның 21 июлендәге
87 номерлы боерыгына
кушымта

**Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибе (алга таба – Тәртип) 2006 елның 02 маендагы “Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү турында” 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясын һәм 2003 елның 12 маендагы “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

1.2. Тәртип, гражданнардан мөрәҗәгатьләр килүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм юк итү максатында, Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына (алга таба – Дәүләт комитеты) гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау буенча критерийларны һәм шартларны билгели.

2. Дәүләт комитетына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибе

2.1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм аларга анализ ясау Дәүләт комитетына гражданнардан килүче мөрәҗәгатьләргә анализ ясау өчен җаваплы булган вазифаи зат (алга таба – вазифаи зат) тарафыннан башкарыла, ул Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе (алга таба – рәис) тарафыннан билгеләнә. Дәүләт комитетына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау ешлыгы, – елга ике тапкыр: яртыеллык һәм узган ел өчен.

2.2. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм аларга анализ ясау вазифаи зат тарафыннан, Татарстан Республикасында Бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы (алга таба – БВЭДӘС) ярдәмендә, хисап чорында Дәүләт комитетына гражданнардан килгән, шул исәптән язмача рәвештә, электрон хәбәрләр рәвешендә, шулай ук турыдан-туры Дәүләт комитетының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты (http://tourism.tatarstan.ru) (алга таба – рәсми сайт) аша җибәрелгән барлык мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып башкарыла.

2.3. Дәүләт комитетына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясаганда гражданнарны шәхси кабул итү буенча Тәртипкә карата Кушымта рәвешендә төзелгән карточкаларда теркәлгән гражданнарның мөрәҗәгатьләре зарури тәртиптә исәпкә алына.

2.4. Дәүләт комитетына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ ясаганда гражданнарның мөрәҗәгатьләренең сан һәм сыйфат ягыннан сыйфатламалары исәпкә алына, гражданнарның мөрәҗәгатьләрендә китерелгән сорауларның төп тематикасы аерып чыгарыла, шулай ук Дәүләт комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү нәтиҗәлелеген, аларның үтәлеш срокларын контрольдә тоту сыйфатын арттыруга йогынты ясаучы чаралар исемлеге төзелә.

2.5. Дәүләт комитетына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә карата ясалган анализ нәтиҗәләре буенча вазифаи зат, хисап чоры тәмамланганнан көннән соң бишкөнлек срокта, хисап чорында Дәүләт комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында аналитик белешмә (алга таба – аналитик белешмә) төзи һәм аны рәискә, БВЭДӘС ярдәмендә, аналитик белешмәне төзү көнендә электрон документ рәвешендә тапшыра.

2.6. Аналитик белешмә түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш (хисап чоры өчен):

гражданнардан килгән, башка адреска җибәрелгән һәм карап тикшерелгән язмача мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны турында;

гражданнардан килгән, башка адреска җибәрелгән һәм карап тикшерелгән электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны турында;

гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында;

шәхси кабул итү барышында кабул ителгән гражданнарның саны турында;

гражданнарны шәхси кабул итү һәм урынга чыгып шәхси кабул итү буенча вәкаләт бирелгән затлар турында;

гражданнарның мөрәҗәгатьләренең тематикасы турында;

гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү нәтиҗәсендә кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый актлар һәм бүтән төрле актлар (булган очракта) хакында мәгълүмат.

2.7. Дәүләт комитетына яртыеллыкта һәм узган елда гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә ясалган анализ Дәүләт комитетының рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру өчен җаваплы булган хезмәткәр тарафыннан елга ике тапкыр: 10 июльдән һәм 10 гыйнвардан да соңга калмыйча, рәсми сайтның “Мөрәҗәгатьләр һәм гражданнарны кабул итү” бүлегендә урнаштырыла.

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2015 елның
21 июлендәге 87 номерлы
боерыгы белән расланган
Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетына килгән
гражданнарның мөрәҗәгатьләренә
анализ ясау тәртибенә карата
кушымта

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты

Гражданнарны шәхси кабул итү карточкасы

Фамилиясе__________________________________________________
Исеме______________________________________________________
Атасының исеме (булган очракта)________________________________
Җавап җибәрү өчен почта адресы________________________________
(кирәк булганда)
__________________________________________________________

Кабул итү көне______________________________________________
Телдән мөрәҗәгатьнең кыскача эчтәлеге__________________________
__________________________________________________________
__________________________________________________________
__________________________________________________________
Кем кабул итте______________________________________________
(вазифасы, Ф.И.А.)
__________________________________________________________
Язмача мөрәҗәгать кабул ителде. Шушында җибәрелде________________
__________________________________________________________
___________________________________ «____» ___________ 20 ___ел.
Теркәү номеры_______________________________________________
Кабул итү нәтиҗәләре турында мәгълүмат_________________________
__________________________________________________________
__________________________________________________________
__________________________________________________________
__________________________________________________________
Искәрмә____________________________________________________

Телдән җавап алуга риза______________________________________
Имза_______________________________________________________

Мөрәҗәгатьне карап тикшерү максатларында шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә һәм саклауга риза________________________________________

Имза ________________________________________

________________________________